**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5536

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тургай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 гыйнварендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тургай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе – «Тургай» балалар бакчасы тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 20 октябрендәге 3519 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5536 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Тургай» балалар бакчасы буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Күңелле ритмика» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Говорунишки» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Белем шатлыгы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 4 | «Яшь шахматчы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 5 | «Тестопластика» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 6 | «Всезнайка» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 7 | «Балалар финтнесы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 8 | «Сөйләм ритмикасы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Тургай» балалар бакчасы мөдире ________________ Л.К. Фәрхтетдинова

ДЕТСКИЙ САД «ТУРГАЙ»

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ________________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе - «Тургай» балалар бакчасы тарафыннан түләүле хезмәт күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Күңелле ритмика»** - программа ритмика нигезләрен, классик бию әлифбасын үзләштерүне, бию элементларын өйрәнүне, балалар бал һәм халык биюләрен башкаруны күздә тота. Бию-музыкаль импровизациягә сәләт тәрбияләү. Хореография дәресләрендә балалар ишетү, күрү, мускул хәтерен үстерәләр, нәзакатьле гадәтләргә өйрәнәләр. Тәрбияләнүче биюнең күптөрлелеген белә: классик, халык, бал, заманча һ.б. Хореография аралашучанлык, тырышлык, максатларга ирешү осталыгын тәрбияли, аралашуның эмоциональ культурасын формалаштыра. Әлеге хезмәт 3 яшьтән 5 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 70 кв.м., балалар саны - 28. Атнага бер тапкыр.

2. **«Говорунишки»** - логопедия түгәрәге программасы балаларга аваз әйтелешен камилләштерү, вак һәм эре моторика, фонематик ишетү, мәктәпкәчә учреждение шартларында артикуляция үсеше аша сөйләмне активлаштыру өчен махсуслаштырылган логопедия ярдәме күрсәтергә мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәт 3 яшьтән алып 4 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы - 15 кв.м., балалар саны - 10. Атнага бер тапкыр.

3. **«Белем шатлыгы»** - үстерүче уеннардан файдалану юлы белән өлкән мәктәпкәчә яшьтәге балаларның танып-белү процессларын үстерү. Программаны гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешүне күздә тота: акыл гамәлләрен үзләштерү, планлаштыру, үз гамәлләреңне хәл итү һәм тикшерү; иң гади акыл бәяләмәләре төзү күнекмәләренә ия булу; сөйләмне үстерү; математик эчтәлектәге үстерүче уеннарга кызыксыну арту. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 25. Атнага бер тапкыр.

4. **«Яшь шахматчы»** - логик һәм математик фикерләүне, спорт-танып белү юнәлешен үстерүгә юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 5 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы - 15 кв.м., балалар саны - 30. Атнага бер тапкыр.

5. **«Тестопластика»** - эре һәм вак моторика, хәтер үсешенә юнәлтелгән. Әлеге хезмәт 4 яшьтән алып 5 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 20. Атнага бер тапкыр.

6. **«Всезнайка»** - элементар математик күзаллауларны формалаштыруга, сөйләмне, фикерләүне, хәтерне, игътибарны, коммуникатив белемнәрне, күзаллауларны үстерүгә юнәлдерелгән. Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 19. Атнага бер тапкыр.

7. **«Балалар финтнесы»** - программа ритмик, эмоциональ музыканы һәм бию күнегүләрен берләштерүгә нигезләнгән. Дәресләр чыдамлык, хәрәкәтләрне координацияләү, көч һәм сыгылмалылык кебек сыйфатларны үстерү өчен күнегүләрне гармонияле рәвештә берләштерергә мөмкинлек бирә. Әлеге хезмәт

3 яшьтән 5 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 70 кв.м., балалар саны - 15. Атнага бер тапкыр.

8. **«Сөйләм ритмикасы»** - программа коррекция-үсеш юнәлешле, баланы сөйләм бозуы белән социаль җайлаштыруга ярдәм итә һәм логопедик коррекция максатларында башкарыла торган музыкаль-хәрәкәт, сөйләм, музыкаль-сөйләм биремнәре һәм күнегүләр системасыннан гыйбарәт. Әлеге хезмәт 3 яшьтән 5 яшькә кадәрге балаларга бирелә, кабинетның мәйданы 50 кв.м., балалар саны - 21. Атнага бер тапкыр.

ТР Тукай муниципаль районы
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе - «Тургай» балалар
бакчасы мөдире _______________ Л.К. Фәрхтетдинова
Ю.В. Хөсәинова

ДЕТСКИЙ САД «ТУРГАЙ» ИНН 1639059306